ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«26» сентября 2022 ел** **№ 173**

**Арча муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил эшчеләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча район ведомствоара комиссиясе төзү турында**

Арча муниципаль районында халыкның тормыш-көнкүрешен яхшырту, формаль булмаган хезмәт базарын киметү һәм икътисадтагы тискәре тенденцияләрне бетерү буенча эшчәнлек алып баруны тәэмин итү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Арча муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил эшчеләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Арча муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил эшчеләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча район ведомствоара комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

3. Арча муниципаль районы башлыгының "Арча муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил эшчеләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча район ведомствоара комиссиясе төзү турында" 2014 елның 24 февралендәге 39-1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга (17.03.2014 № 51; 09.06.2014 № 99; 05.04.2017 № 60; 13.06.2018 № 40; 12.11.2018 № 92; 17.12.2019 № 157; 19.03.2020 №29; 12.02.2020 №81; 03.11.2020 № 134; 13.08.2021 №114; 07.02.2022 № 29 үзгәрешләр белән).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Д. Шаһиәхмәтовка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы И.Г. Нуриев

*Арча муниципаль районы башлыгының*
*«26» сентябрь 2022 ел, № 173*
*карарына 1 нче кушымта*

**Арча муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил эшчеләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә**

1. Арча муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил эшчеләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча район ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, формаль булмаган хезмәт базарын киметү һәм икътисадтагы тискәре тенденцияләрне бетерү, шулай ук Арча районында чит ил эшчеләрен җәлеп итүдә катнашу максатыннан оештырылды.

2. Комиссия үз эшчәнлеген гамәлдәге законнар һәм әлеге нигезләмә нигезендә башкара.

3. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре:

- Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе карарларын үтәү;

-социаль-икътисади өлкәнең агымдагы торышына мониторинг үткәрү;

- Арча муниципаль районы икътисадында хезмәт базарын тотрыклыландыру, керемнәрне легальләштерү, күләгә икътисады һәм формаль булмаган хезмәт базары йогынтысы нәтиҗәсендә килеп чыккан тискәре тенденцияләрне бетерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү;

- минималь куллану бюджеты һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына эш бирүчеләрнең иминият кертемнәрен түләү, халыкның, шул исәптән пенсия яшендәге гражданнарның реаль керемнәрен арттыру, шулай ук эш бирүчеләрнең пенсия яшенә җитмәгән затлар белән үзара хезмәттәшлек итүләре буенча эшчәнлекне координацияләү чараларын эшләү;

- оешмаларда барлыкка килгән бурычлар буенча хезмәт хакын түләү торышын анализлау, хезмәт хакын түләмәүнең сәбәпләрен тикшерү;

- хезмәт хакы буенча бурычларны түләүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм кабул итү, аларның үтәлешен контрольдә тоту;

- милекчеләр тарафыннан үз вакытында идарәчел карарлар кабул итү һәм хуҗалык итүче субъектларның түләүгә сәләтсезлеген үстерүгә яки белә торып формалаштыруга юнәлтелгән гамәлләр кылу өчен тәкъдимнәр эшләү максаты белән кризис хәлендә булган хуҗалык итүче субъектлар эшчәнлегенә мониторинг;

- законнар нигезендә башка функцияләрне гамәлгә ашыру.

4. Комиссиянең хокуклары:

- Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә предприятие, учреждение һәм оешма җитәкчеләрен тыңлау;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан хуҗалык итүче субъектлардан Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тиешле документларны билгеләнгән тәртиптә соратып алу;

- Комиссия тарафыннан ачыкланган бозуларны бетерү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Арча муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә закон нигезендә карарлар кабул итү өчен мәгълүмат җибәрү;

- Комиссия эшенә ярдәм итү өчен хокук саклау органнарын, шулай ук дәүләт күзәтчелеген һәм контрольне гамәлгә ашыручы башка органнарны комиссия һәм күрсәтелгән органнар арасында төзелгән тиешле килешүләр нигезендә җәлеп итү, аларга Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча киңәшләр бирү;

- кирәк булганда, Комиссия компетенциясенә караган карарлар һәм башка материаллар әзерләүдә катнашу өчен Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Арча муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, хуҗалык итүче субъектларны тиешле тәртиптә җәлеп итү;

- Комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча эшче төркемнәр төзү.

5. Комиссия Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

6. Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен алмаштыру хокукыннан башка җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыралар.

7. Комиссия составы Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана. Комиссия үз эшчәнлеген Комиссия рәисе раслаган план буенча гамәлгә ашыра.

8. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма айга кимендә бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары анда катнашучыларның гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышында рәислек итүче тавышлары тигез булган очракта, хәлиткеч тавыш санала. Утырыш беркетмәсенә Комиссия рәисе яисә аның урынбасары кул куя.

9. Комиссия рәисе:

- Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

- Комиссия эшчәнлеген тәэмин итә торган карарлар кабул итә;

- Комиссия әгъзаларының эшен координацияли, чираттагы утырышта каралырга тиешле мәсьәләләр даирәсен билгели;

- үз вәкаләтләре кысаларында Комиссия эше нәтиҗәләре буенчак арарлар кабул итә, шулай ук Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе рәисенә тиешле тәкъдимнәр кертә.

10. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда, аның вазыйфаларын рәис урынбасары башкара.

11. Комиссия секретаре:

- Комиссия утырышларына әзерлекне оештыра, төрле хезмәтләрдән алынган мәгълүматны җыю һәм гомумиләштерүне контрольдә тота, статистик мәгълүматларга анализ ясый;

- Комиссия компетенциясендә булган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә хуҗалык итүче субъектлардан мәгълүмат соратып ала;

- Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

- Комиссия кабул иткән карарларның үтәлеше турында мәгълүмат әзерли.

12. Аның компетенциясе кысаларында кабул ителгән Комиссия карарлары учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар тарафыннан оештыру-хокукый формаларына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә үтәлергә тиеш.

13. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге тарафыннан башкарыла.

*Арча муниципаль районы башлыгының «26» сентябрь 2022 ел, №173 карарына 2 нче кушымта*

**Арча муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил эшчеләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча район ведомствоара комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Ренат Мансурович | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Шаһиәхмәтов Радик Дамирович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Галимуллина Гүзәл Харисовна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Абдуллин Ленар Илсурович | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Әхмәтгалиев Булат Данилович | - Арча шәһәрендә Дәүләт статистикасы бүлегенең баш белгеч-эксперты (килешү буенча); |
| Галимова Светлана Петровна | - «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Галәветдинов Алмаз Рифатович | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлегенең икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы тору төркеменең өлкән оперуполномоченные (килешү буенча); |
| Гафурова Илмира Шәйхулловна | - РФ Социаль иминият фондының ТР буенча төбәк бүлекчәсе (Арча районы) дәүләт учреждениесенең 8 нче филиалы баш белгече (килешү буенча); |
| Гыйбадуллина Гөлфия Мансуровна | - «Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Закиров Эдуард Айдарович | - Арча районара тикшерү бүлеге җитәкчесе, юстиция майоры (килешү буенча); |
| Җәләлиева Лилия Тәбрисовна | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районында Республика матди ярдәм үзәгенең 10 нчы филиалы директоры (килешү буенча); |
| Лошакова Ольга Владимировна | - РФ Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлегенең миграция мәсьәләләре буенча бүлек җитәкчесе (килешү буенча); |
| Лотфуллин Алмаз Камилевич | - Россия Суд приставлары федераль хезмәте ТР буенча идарәсенең Арча районара суд приставлары бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Мифтахетдинова Надия Равилевна | - Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Арча муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Мөгыйнова Светлана Александровна | - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 5 нче районара инспекциясенең 6 нчы федераль тикшерүләр бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Сираҗиев Илһам Гаптелнурович | - Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Нурмөхәмәтова Рузия Илсуровна | - Россия Федерациясе Пенсия фонды идарәсенең Татарстан Республикасы Саба районы буенча Арча районында клиентлар хезмәте җитәкчесе (бүлек хокукларында) (килешү буенча); |
| Шакирова Миләуша Ниязовна | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча). |